**<u>Татар халык җыры</u>**

# ЗАМАН

Гафил булган татарларны
Ник уятмыйсың, заман?

Аһ, син, заман, заман, заман,
Ник уятмыйсың һаман?

Аңлат гыйлем кирәклеген,
Тормасын алар надан.

Аһ, син, заман, заман, заман,
Ник аңлатмыйсың һаман?

Сахра, галәм, мәйдан алып,
Хакыйкать аста калган.

Аһ, син, заман, заман, заман,
Ник кузгатмыйсың һаман?